РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» ноябрь 2022ел г. Альметьевск № 2729

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы башкарма
комитетының «Әлмәт муниципаль
районының типик булмаган муниципаль
учреждениеләре хезмәткәрләре,
шулай ук Әлмәт муниципаль
районының ведомство буйсынуындагы
учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин
итүче хезмәткәрләр өчен премияләр
бирү һәм башка өстәмә түләүләр
турында типлаштырылган нигезләмәләрне
раслау хакында» 2018 елның
18 октябрендәге 1694 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районының типик булмаган муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре, шулай ук Әлмәт муниципаль районының ведомство буйсынуындагы учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәткәрләр өчен премияләр бирү һәм башка өстәмә түләүләр турында типлаштырылган нигезләмәләрне раслау хакында» 2018 елның 18 октябрендәге 1694 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы дүртенче абзацында:

а) «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Торак сәясәте һәм торак - коммуналь хуҗалык департаменты» сүзләрен «Үсеш департаменты» муниципаль автоном учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.;

б) «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Экология һәм табигатьтән файдалану департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Экология һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

в) «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2 нче кушымтаның 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Вазыйфаи окладка айлык өстәмә билгеләнә:

Зак. № 305-2000

Фәннәр кандидатының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 1,5 процентыннан артмаган күләмдә;

Фәннәр докторының профильле гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 2 процентыннан артмаган күләмдә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.:

1.1. пунктының а) пунктчасы өчен - 2022 елның 31 гыйнварыннан;

1.1. пунктының б) пунктчасы өчен - 2020 елның 3 июленнән;

1.1. пунктының в) пунктча өчен - 2020 елның 13 маеннан;

1.2. пункты өчен - 2022 елның 1 гыйнварыннан.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

Республика Татарстан муниципальное образование «Альметьевский муниципальный район» Татарстан Республикасы «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
Р.06-12061/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ИНН 1644035822
КПП 164401001
ОГРН 1051605067172